ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«18» 01 2020 г.

**КАРАР**

№ 13

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Шеңшеңәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча гавами (ачык) тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 28 статьялары, Балтач муниципаль районы Уставының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2007 елның 24 мартындагы 66 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гавами тыңлаулар үткәрү турында» Нигезләмә нигездә, кешенең уңай тормыш шартларына хокукларын, «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:

1. Шеңшеңәр авыл җирлеге халкы катнашында «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Шеңшеңәр авылы гражданнары өчен «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 13:00 сәгатьтән 13:30 сәгатькә кадәр Шеңшеңәр мәдәният йортында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Шеңшеңәр авылы, Г.Тукай урамы, 57 нче йорт.

3. Ор авылы гражданнары өчен «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча гавами тыңлауларны 2020 елның 15 февралендә 14:00 сәгатьтән 14:30 сәгатькә кадәр Ор авыл клубында түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Ор авылы, М. Җәлил урамы, 35 нче йорт.

4. Балтач муниципаль районының «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең территорияне территориаль планлаштыруның шәһәр төзелеше документларын әзерләү буенча комиссиясенә (алга таба - Комиссия) гавами тыңлаулар үткәрүне оештырырга.

5. Комиссиягә «Шеңшеңәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы буенча демонстрацион материаллардан күргәзмә-

экспозицияләр оештырырга, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң, тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә.

6. Генераль план проекты буенча гражданнардан тәкъдимнәр әлеге карар басылып чykканнан соң бер ай эчендә Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Балтач районы, Шеңшеңәр авылы, Г.Тукай урамы, 60 нчы йорт.

7. Әлеге карарны Балтач муниципаль районының baltasi.tatar.ru рәсми сайтында һәм Шеңшеңәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач
муниципаль районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин